**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Югары Стәрле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Югары Стәрле авылы №69-43 11 октябрь 2017 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) идарәсендә түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Югары Стәрле авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) идарәсендә түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт алу тәртибе турындагы нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Л.С. Сабирҗанова